# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Яңа Чүте торак пунктында

2021 елның 18 декабре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Яңа Чүте торак пунктында гражданнар җыены

Карар:

1. 2022 елда Баулы муниципаль районы Яңа Чүте авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертү (көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш).

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Тукай урамы, Яңа Чүте авылы буенча урнашкан 129-нчы номерлы йорттан 139-нчы номерлы йортка кадәр юлны төзекләндерү;
- җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда төзекләндерү һәм карап тоту.

Гражданнар җыенында рәислек итүче З. С. Галләметдинов

Салих авыл җирлеге башлыгы З. С. Галләметдинов